РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
14.02.2020 № 2

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2012 нче елның 19 нчы июлендә кабул ителгән 20 нче номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2019 ел, №432-ФЗ Федераль закон һәм «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2019 ел, №48-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан РеспубликасыСабамуниципаль районы Шәмәрдән

Авыл җирлеге Советының 2012 нче елның 19 нчы июлендә кабул ителгән 20 нче номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 20.3.пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм төшерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

1.2 пунктның 6) 12.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, электрон документ формасында.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гәрәев